# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «ЯҢА ТРОИЦКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

26.09.2016 № 9/1

**Яңа Троицкий авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «җирле референдум турында»2004 елның 25 мартындагы 23 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 статьялары, Яңа Троицкий авыл җирлеге Уставы нигезендә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Яңа Троицкий авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе белән берлектә Яңа Троицкий авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында инициативаны тәкъдим итәргә.

«2016 елда яшәү урыны буенча Яңа Троицкий авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 200 ( ике йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 100 (йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы :

1) Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

- Яңа Троицкий авылының 1 нче зиратына кадәр юлны ремонтлау - 40000 сум;

- Яңа Троицкий авылының 2нче зиратына кадәр булган юлны ремонтлау-73200 сум;

- Шөкрәле авылы зиратына кадәр юлны ремонтлау - 14300 сум.

2). Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Троицкий авылының Үзәк урамы буенча юлларны ремонтлау - 28 300;
- Суровка авылында тротуар төзү - 90000 сум;
- Яңа Троицкий авылында тротуар төзү - 50 000 сум.

2. Әлеге карарны Тукай территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Тукай муниципаль районы порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Волкова